**Татарстан Республикасы**
**Ютазы муниципаль районы**
**Ютазы авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

№18 «30» декабрь 2016 ел

*Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге милкендәге мөлкәтне арендага бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында*

Россия Федерациясе Гражданлык кодексына, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131 – ФЗ санлы Федераль законга, 2006 елның 26 июлендәге «Конкуренцияне яклау турында»гы 135 – ФЗ санлы Федераль законга, 1998 елның 29 июлендәге «Россия Федерациясендә бәяләү эшчәнлеге турында»гы 135 – ФЗ санлы Федераль законга, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45 – ТРЗ санлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, Ютазы муниципаль районы Советының 2012 елның 12 июнендәге 14 санлы карары белән кабул ителгән Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге Уставына таянып, Ютазы авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге милкендәге мөлкәтне арендага бирү тәртибе турында»гы кушымтадагы нигезләмәне расларга.
2. Әлеге карарны Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Законлылык, регламент һәм җирлек Советлары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Ютазы авыл җирлеге
башлыгы: Г.Г. Сәфиуллина